ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.12.2022 п.г.т.Алексеевское № 580

**23.04.2019 ел, №167 «Алексеевск муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 09.08.2022 ел, № 03-16/5605 «Шәһәр һәм авыл җирлекләре үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренең һәм белгечләренең һәм бухгалтерларының хезмәтенә түләү турында»гы хатын исәпкә алып

**карар бирәм**:

1. 23.04.2019 ел, № 167 «Алексеевск муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында»Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МБУнең, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирлекләренең Бухгалтериясе» МКУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Җитәкче һәм белгеч вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен, ул структур бүлекчә булса(Башкарма комитетның, башка җирле үзидарә органының бүлекчәсе) |
| Муниципаль учреждение | 27700 | |

| | | |
|---|---|---|
| җитәкчесе | | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 25500 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 25500 |
| Бүлек җитәкчесе | 21700 | 21700 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 19300 | 19300 |
| Бухгалтер | 18000 | 18000 |

Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерияне штат расписаниесенә кертү шарты булып, җитәкче урынбасарының вазыйфасы структурада һәрберсендә кимендә 5 берәмлек штат саны булган кимендә 3 бүлек булу тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләре ким дигәндә 5 штат берәмлеккә ия булырга тиеш.»

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе О.Н.Леденцовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А. Гайнуллин**